КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 февраль г.Казань № 125

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 2 ноябрь, 1000 нче, 2020 ел, 25 февраль, 144 нче, 2021 ел, 2 апрель, 208 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 июль, 636 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 14 февраль, 125 нче
карары редакциясендә)

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасы

I. Гомуми нигезләмәләр

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча әлеге төбәк программасы (алга таба - Төбәк программасы) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкы өлешен, шул исәптән үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлешен арттыру максатларында эшләнде.

II. Төбәк программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасы |
| Төбәк программасы-ның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Төбәк программасын төп эшләүче | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Төбәк программа-сының максатлары | 2024 елга түбәндәге күрсәткечләр мәгънәләренә ирешүне тәэмин итү:<br>үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше – 94,303 процент;<br>үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкы өлеше – 97,475 процент |
| Төбәк программа-сының бурычлары | Перспективалы технологияләрдән файдаланып, оборона-сәнәгать комплексы оешмалары эшләгән технологияләрне дә кертеп, су белән тәэмин итү системаларын |

<table>
<tr><td></td><td>модернизацияләү юлы белән эчә торган суның сыйфатын яхшырту</td></tr>
<tr><td>Төбәк программасын гамәлгә ашыру сроклары</td><td>2019 - 2024 еллар</td></tr>
<tr><td>Төбәк программасында катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре</td><td>Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге</td></tr>
<tr><td>Гамәлгә ашырыла торган чаралар</td><td>«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы тәүлегенә 5 мең куб метрлы Болгар шәһәре су алу станциясе реконструкциясе»;<br>«Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше»;<br>«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзәге булган су белән тәэмин итү системасын төзү»;<br>«Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесен су белән үзәкләштерелгән тәэмин итү системалары объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме</td><td>2019 - 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 1 870 114,71 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барысы</th><th colspan="3">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш чаралар</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>80 444,72</td><td>4 822,0</td><td>20 556,82</td><td>55 065,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>54 134,45</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>54 134,45</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>269 351,55</td><td>26 391,58</td><td>112 510,88</td><td>130 449,09</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>379 081,36</td><td>53 025,46</td><td>226 055,9</td><td>100 000,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>481 878,24</td><td>53 812,36</td><td>229 410,6</td><td>198 655,28</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>605 224,39</td><td>252 809,91</td><td>153 759,2</td><td>198 655,28</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 870 114,71</td><td>390 861,31</td><td>742 293,4</td><td>736 960,0</td></tr>
</table>
Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре</td><td>Программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 ел нәтиҗәләре буенча күрсәткечләр мәгънәләренә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Татарстан Республикасы халкының өлеше - 94,303 процент, шул исәптән:<br>2019 ел - 92,8 процент;<br>2020 ел - 93,018 процент;<br>2021 ел - 93,463 процент;<br>2022 ел - 93,463 процент;<br>2023 ел - 93,463 процент;<br>2024 ел - 94,303 процент;<br>үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкының өлеше - 97,475 процент, шул исәптән:<br>2019 ел - 96,11 процент;<br>2020 ел - 96,383 процент;<br>2021 ел - 96,383 процент;<br>2022 ел - 96,383 процент;<br>2023 ел - 96,383 процент;<br>2024 ел - 97,475 процент;<br>Төбәк программасы чаралары яшәү өчен уңайлы мохит булдыруга һәм халыкның яшәешенә ярдәм итәчәк.<br>Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпләү VIII бүлектә китерелгән |

## III. Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының агымдагы торышына сыйфатлама, Татарстан Республикасында эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшыртуга ярдәм итә торган чаралар тасвирламасы

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча, 2021 елның 1 гыйнварына торышы буенча Татарстан Республикасында су үткәргеч челтәрләрнең озынлыгы 18,57 мең км тәшкил итә, шуларның 5,93 мең км (31,93 процент) алмаштырырга кирәк, су белән тәэмин итү челтәрләренең тузуы - 49,3 процент.

Чиста су булмау халыкның сәламәтлегендә чагыла һәм йогышлы авырулар таралу, авыруларны үстерү, төрле факторларның кешенең организмына йогынты ясау куркынычы дәрәҗәсен арттыру сәбәбе булып тора. Барлык авыруларның 20 процентка якыны суның канәгатьләнерлек булмаган сыйфаты белән бәйле булырга мөмкин.

2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларының торышын бәяләү йомгаклары буенча (инвентаризация) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлеше 93,58 процент тәшкил итте, шул исәптән:

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән шәһәр халкы өлеше – 96,79 процент;

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән авыл халкы өлеше – 82,09 процент;

Төбәк программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшыртачак 4 чараны башкару планлаштырыла, шул исәптән:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы тәүлегенә 5 мең куб метрлы Болгар шәһәре су алу станциясе реконструкциясе». Болгар шәһәрендә эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проект гамәлдәге су җыю җайланмасының җитештерүчәнлеген арттыруны һәм тәүлегенә 5 мең кубометр проект куәте булган су үткәргеч чистарту станциясе төзүне күздә тота. Суны эчә торган сыйфатка кадәр чистарту өчен, гадиләштерелгән аэрация белән кайнар фильтрлар кулланып, бербаскычлы чистарту кабул ителде.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 8 476 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,218 процентка арттырып.

2. «Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше». Васильево шәһәр тибындагы поселогында эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проект белән тәүлегенә 4 мең кубометр проект куәте булган су әзерләү станциясен төзү каралган. Суны эчәргә яраклы сыйфатка кадәр чистарту кире осмос җайланмасында алга таба зарарсызландыру белән каралган.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 17 341 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,445 процентка арттырып.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзәге булган су белән тәэмин итү системасын төзү». Нурлат шәһәрендә поселогында эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проектта Чирмешән чыганагы территориясендә Чулпан авылы янында скважиналар бораулау, насос станцияләре төзү, тәүлегенә 10 мең куб метр су әзерләү куәте белән су әзерләү станциясенә кадәр суүткәргеч салу каралган. Суны эчәргә яраклы сыйфатка кадәр чистарту алга таба зарарсызландыру белән тирән аэрация булган ашыгыч фильтрларда каралган.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 32 703 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,84 процентка арттырып.

Барлык чаралар Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан килештерелде.

4. Шулай ук Төбәк программасы кысаларында чаралар Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе акчалары исәбеннән «Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесен су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү» объекты буенча гамәлгә ашырыла.

1 нче таблица

Төбәк программасы чаралары

| Т/с | Чараның исеме | Объектны эксплуатациягә керткәннән соң үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин ителгән халык санының артуы, мең кеше | Объектны эксплуатациягә керткәннән соң үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин ителгән халык өлеше, процент | Эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми торган күрсәткеч |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | «Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше» | 17 341 | 0,445 | суның катылыгы, тимер, марганец һәм башка күрсәткечләрнең гомуми күләме норматив күрсәткечләрдән артып китә |
| 2. | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзеге булган су белән тәэмин итү системасын төзү» | 32 703 | 0,840 | |
| 3. | «ТР Спас муниципаль районының тәүлегенә 5 мең куб метрлы су алу системасы реконструкциясе» | 8 476 | 0,218 | |
| Барлыгы | | 58 520 | 1,503 | |

## IV. Төбәк программасының максатлары һәм бурычлары, көтелгән соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Төбәк программасының максатлары түбәндәгеләр:

«үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәр су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкы өлеше» күрсәткеченең 2024 елга мәгънәсенә ирешүне 94,303 процентка кадәр тәэмин итү;

«үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәр су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкы өлеше» күрсәткеченең 2024 елга мәгънәсенә ирешүне 97,475 процентка кадәр тәэмин итү.

Бурычлар: перспективалы технологияләрдән файдаланып, оборона-сәнәгать комплексы оешмалары эшләгән технологияләрне дә кертеп, су белән тәэмин итү системаларын модернизацияләү юлы белән эчә торган суның сыйфатын яхшырту.

2019 - 2024 елларда Төбәк программасы максатларына ирешү һәм бурычларын үтәү өчен Татарстан Республикасының дүрт муниципаль районында су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү буенча чаралар гамәлгә ашырылачак.

Программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 ел нәтиҗәләре буенча күрсәткечләр мәгънәләренә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше - 94,303 процент, шул исәптән:

2019 ел - 92,8 процент;

2020 ел - 93,018 процент;

2021 ел - 93,463 процент;
2022 ел - 93,463 процент;
2023 ел - 93,463 процент;
2024 ел - 94,303 процент;

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкының өлеше - 97,475 процент, шул исәптән:

2019 ел - 96,11 процент;
2020 ел - 96,383 процент;
2021 ел - 96,383 процент;
2022 ел - 96,383 процент;
2023 ел - 96,383 процент;
2024 ел - 97,475 процент;

## V. Төбәк программасына кертелгән су әзерләүнең перспектив технологияләреннән файдалануга күчү тәртибе

Төбәк программасын гамәлгә ашырганда, 2019 елның 17 июлендә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган оборона-сәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан эшләнгән технологияләрдән файдаланып, су әзерләүнең һәм чистартуның перспектив технологияләре белешмәлеге кулланылачак. Проект-смета документациясен эшләгәндә белешмәлектә күрсәтелгән технологияләр кулланылачак.

## VI. Төбәк программасын ресурслар белән тәэмин итү

2019 - 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 1 870 114,71 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш чаралар |
| 2019 | 80 444,72 | 4 822,0 | 20 556,82 | 55 065,9 |
| 2020 | 54 134,45 | 0,0 | 0,0 | 54 134,45 |
| 2021 | 269 351,55 | 26 391,58 | 112 510,88 | 130 449,09 |
| 2022 | 379 081,36 | 53 025,46 | 226 055,9 | 100 000,0 |
| 2023 | 481 878,24 | 53 812,36 | 229 410,6 | 198 655,28 |
| 2024 | 605 224,39 | 252 809,9 | 153 759,2 | 198 655,28 |
| Барлыгы | 1 870 114,71 | 390 861,31 | 742 293,4 | 736 960,0 |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## VII. Төбәк программасын гамәлгә ашыру механизмы

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы Төбәк программасын планлаштыруны, үзара бәйләнешне, координацияне һәм аның үтәлешенә гомуми контрольне гамәлгә ашыра.

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Төбәк программасы чаралары исемлеген килештерүне тәэмин итә, Төбәк программасын гамәлгә ашыруда катнашучыларга методологик ярдәм күрсәтә.

Бюджет чараларын алучы һәм Төбәк программасы чараларын башкаручы булып «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләренең баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе тора, ул сатулар, аукционнар оештыруны һәм уздыруны, дәүләт контрактлары төзүне гамәлгә ашыра, заказчы-төзүче функцияләрен үти, проект документациясенә экспертиза уздыруны тәэмин итә, төзелеш контролен гамәлгә ашыра.

Төөбәк программасын гамәлгә ашырганда социаль һәм экологик куркынычлар юк.

## VIII. Федераль бюджеттан инвестицияләрнең бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткече объектка җибәрелә торган федераль бюджеттан үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителмәгән авыл халкының планлы күрсәткеченә инвестицияләр күләме нисбәте буларак билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\frac{V}{P} = E,$$

монда:

V – федераль бюджеттан инвестицияләр күләме, мең сум;

P – Россия Федерациясе субъекты халкының гомуми санына карата үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлешен арттыру, процентлар;

E - бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткече, сум/процент.

2 нче таблица

Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| Рейтингта позиция | Чараның исеме | Татарстан Республикасы халкының гомуми санына китерелгән үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлешен арттыруның план күрсәткече, процентлар | Федераль бюджеттан инвестицияләр күләме, мең сум | Бюджет нәтиҗәлелеге, мең сум /процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль рай- | 0,218 | 20 556,82 | 94 297,34 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | оны тәүлегенә 5 мең куб метрлы Болгар шәһәре су алу станциясе реконструкциясе | | | |
| 2. | Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше | 0,445 | 112 510,88 | 252 833,44 |
| 3. | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзәге булган су белән тәэмин итү системасын төзү | 0,84 | 609 225,70 | 725 268,69 |
| Барлыгы | | 1,503 | 742 293,40 | 493 874,52 |

Чараларны гамәлгә ашыру чираты проект-смета документациясе булуны, проект-смета документациясен эшләүгә акчалар бүлеп бирү турында һәм Төбәк программасының максатчан күрсәткечләрен ел саен гамәлгә ашыру кирәклеге турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе булуны исәпкә алып билгеләнде.

## IX. Ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның инвестиция программаларында каралган финанс чаралары күләме

2019 - 2024 елларда Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесен су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә каралган финанс чаралары күләме бюджеттан тыш акчалар исәбеннән 736 960,0 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда - 55 065,9 мең сум;
2020 елда – 54 134,45 мең сум;
2021 елда - 130 449,09 мең сум;
2022 елда – 100 000,0 мең сум;
2023 елда - 198 655,28 мең сум;
2024 елда - 198 655,28 мең сум.

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасы объектларына сыйфатлама аңа 1 нче кушымтада бирелгән.

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруны финаслар белән тәэмин итү аңа 2 нче кушымтада бирелгән.

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын гамәлгә ашырганда «Чиста су» федераль проектының максатчан күрсәткечләренә ирешү динамикасы аңа 3 нче кушымтада бирелгән.

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын гамәлгә ашыру этаплары аңа 4 нче кушымтада бирелгән.

2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасы чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренең тариф фаразы аңа 5 нче кушымтада бирелгән.